КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 сентябрь г.Казань № 1193

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында» 2016 ел, 13 апрель, 218 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 апрель, 498 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү тәртибенә, 2 пункттагы «Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «Тәртип нигезендә» сүзләренә алмаштырып, татар текстында «расланган» сүзен үзгәрешсез калдырып, «2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы» сүзләрен «2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2016 ел, 23 декабрь, 976 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 15 декабрь, 1146 нчы; 2021 ел, 25 март, 170 нчы; 2021 ел, 9 июнь, 443 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Торглар үткәрү, торглар нәтиҗәләре буенча мөлкәтне арендалау шартнамәләрен төзү Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе һәм әлеге шартнамәләр конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән төзелә алган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы белән расланган аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

8 пунктта «кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы милкенә яки муниципаль милеккә караган һәм канәгатьләндерерлек булмаган хәлдәге файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына ташламалы аренда түләве билгеләү тәртибен һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирасының Татарстан Республикасы милкенә караган һәм канәгатьләндерерлек булмаган хәлдәге файдаланылмый торган объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 ноябрь, 852 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 март, 160 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирасының Татарстан Республикасы милкенә караган һәм канәгатьләндерерлек булмаган хәлдәге файдаланылмый торган объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибенә, 3 пункттагы «2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы» сүзләрен «2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-

тының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август, 762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 15 июль, 677 нче; 2022 ел, 4 август, 757 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1202 нче; 2023 ел, 3 март, 201 нче; 2023 ел, 1 июнь, 669 нчы; 2023 ел, 3 июль, 773 нче; 2023 ел, 11 июль, 811 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның 18 графасындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм куллануга даими әзер булу хәлендә тоту тәртибе турында» 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы карары;»;

2.2 пунктның 18 графасындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм куллануга даими әзер булу хәлендә тоту тәртибе турында» 2023 елның 17 маендагы 769 номерлы карары;»;

17.29 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе һәм әлеге шартнамәләр конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән төзелә алган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы»;

17.30 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе һәм әлеге шартнамәләр конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән төзелә алган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы»;

17.31 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе һәм әлеге шартнамәләр конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән төзелә алган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы»;

17.32 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт мөлкәтенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар уздыру тәртибе һәм әлеге шартнамәләр конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән төзелә алган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы»;

19.1 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларында саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 31 июлендәге 77 номерлы боерыгы»;

19.3 пунктның 18 графасындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларында саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 31 июлендәге 77 номерлы боерыгы»;

21.11 пунктта:

18 графаның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең «Төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында» 2023 елның 4 апрелендәге 232/551 номерлы боерыгы белән расланган Төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе;»;

18 графаның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең «Урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау

турында» 2023 елның 4 апрелендәге 233/552 номерлы боерыгы белән расланган Төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе;».

5. Бу карар 2023 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин